Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Сөләй авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел

N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Сөләй авыл җирлегенең
Яңа Михайловка авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Яңа Михайловка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 16 ноябренә, 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сөләй авыл җирлегенең Яңа Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү өчен?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын Яңа Михайловка авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Яңа Михайловка авылы, Заречная урамы, 29б йорты.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авылы башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Михайловка авылы, Заречная урамы, 29а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Сөләй авыл
җирлеге башлыгы

А.З. Бикбаев